**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ УРЫССУ БИСТӘСЕ**
**СОВЕТЫ**

# КАРАР № 40

Урыссу штб 29.11. 2024 ел

Җир салымы турында

Россия Федерациясе Салым кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль Законы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, «Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар милкенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында»гы 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә түләү мәҗбүри булган җир салымын (алга таба – салым) билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Билгеләргә:

2.1. Җир кишәрлекләренең кадастр бәясеннән салым ставкалары түбәндәге күләмдә:

1) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә кертелгән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган авыл хуҗалыгы зоналары составындагы җирләргә карата 0,3 %;

2) торак фонды һәм торак-коммуналь комплексы инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килгән җир участогына хокук өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җирләргә карата (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) 0,25%;

3) «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ санлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган (бирелгән) җирләргә карата 0,15 %;

4) "Шәхси ярдәмче хуҗалык турында"гы 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ санлы Федераль законда каралган шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә кулланылмый торган җирләргә карата 0,25% ;

5) максатчан билгеләнеш буенча кулланылмый торган торак пунктларда авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яки авыл хуҗалыгы файдалану зоналары составындагы җирләргә караган җир кишәрлекләренә карата 1,5% ;

6) башка җир кишәрлекләренә карата 1,5%.

2.2. Салым түләүче оешмалар өчен хисап чоры булып календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы тора.

2.3. Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлеше буенча тиешле салым ставкасының 1/4 өлеше күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.

3. Җир кишәрлекләренең кадастр бәясеннән ташламалы салым ставкасын түбәндәге күләмдә бирергә:

1) Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджеттан финанслана торган казна, автоном, бюджет учреждениеләре, идарә органнары тарафыннан биләнгән һәм салым салу объектлары дип танылган җир кишәрлекләренә карата 0,2% ;

2) 1-3 категорияле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата 0,05%.

4. Салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләрен эшкуарлык эшчәнлеге өчен кулланылмый торган җир кишәрлекләре өчен салым түләүдән азат итәргә:

1) Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары;

2) Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, шулай ук хәрби хәрәкәтләр ветераннары һәм инвалидлары;

3) Шәхси торак йортларда яшәүче Бөек Ватан сугышында һәлак булган катнашучыларның тол хатыннары;

4) хезмәт бурычларын үтәгәндә һәлак булган хәрбиләрнең һәм дәүләт хезмәткәрләренең әти-әниләре һәм хатыннары;

5) 1991 елның 15 маендагы «Чернобыль атом электростанциясендәге һәлакәт нәтиҗәсендә радиациягә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында»гы 1244-1 санлы Россия Федерациясе Законы, 1998 елның 26 ноябрендәге «Чернобыль атом электростанциясендәге һәлакәт нәтиҗәсендә радиациягә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында»гы 175-ФЗ санлы Федераль закон, «Маяк» җитештерү берләшмәсендә 1957 елгы авария һәм «Теча» елгасына радиоактив калдыклар ташлау һәм 2002 елның 10 гыйнварындагы «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында»гы 2-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә социаль ярдәм алу хокукына ия булган физик затлар;

6) 2 һәм 3 дәрәҗә хезмәт эшчәнлеге сәләте чикләнгән инвалидлар, шулай ук 1 һәм 2 төркем инвалидлыклары булган кешеләр;

7) балачактан инвалидлар, инвалид балалар;

8) опека астында ятим балалар;

9) авыл җирлегендә яшәүче балалары булмаган ялгыз пенсионерлар;

10) Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары торак төзелеше өчен даими (вакытсыз) файдалануга рәсмиләштерелгән җир кишәрлекләре өлешендә; «авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр» категориясеннән җирләр; бакчачылык, яшелчәчелек алып бару өчен, «Мәктәпкәчә, башлангыч һәм урта гомуми белем бирү» рөхсәт ителгән куллану төре белән, мәктәпләр, су объектлары астында, шул исәптән чишмәләр һәм гидротехник корылмалар астында, су алу скважиналары астында, буалар астында, коммуналь билгеләнештәге объектлар астында, каптажга, насос станциясенә, су суырту башнясы астында, эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрешне су белән тәэмин итү, су үткәрү челтәрләренә һәм корылмаларына хезмәт күрсәтү өчен, балыкчылык өчен, балык тоту һәм аучылык хуҗалыгы объектларын һәм башка су объектларын урнаштыру өчен, складлар, базалар, яшелчә саклагычлары, сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәт күрсәтү объектлары, җитештерү һәм административ биналарны, сәнәгать корылмаларын урнаштыру өчен билгеләнгән җирләр, файдалы казылмалар эшкәртү өчен билгеләнгән җирләр, тимер юллар, автомобиль юллары, торба үткәргеч транспорты урнаштыру, автотранспортка хезмәт күрсәтү өчен, кече базарга хезмәт күрсәтү өчен, мебель фабрикасы, хастаханәләр астындагы җирләр, фельдшер-акушерлык пунктлары, дини билгеләнештәге объектлар астындагы җирләр, шәхси ярдәмче хуҗалык өчен, гаражлар астындагы җирләр, мәйданнар, урамнар, тыкрыклар, юллар, скверлар, парклар, һәйкәлләр, коммуналь объектлар, үләт базлары, каты көнкүреш калдыклары полигоннары, команда пункты, «Спорт» рөхсәт ителгән файдалану төре булган җирләр, балалар мәйданчыклары астындагы җирләр, мәдәни-көнкүреш билгеләнешендәге җирләр, спорт мәйданчыклары астындагы җирләр, «Сабантуй» уздыру урыннары, контейнер мәйданчыклары, иҗтимагый (дәүләт) идарәсе астындагы җирләр, тарихи-мәдәни эшчәнлек өчен, мәдәният объектларын һәм башка гомуми файдаланудагы җирләрне урнаштыру өчен.

11) граждannар җирләү өчен кулланыла торган җир кишәрлекләренә карата оешмалар;

12) ирекле янгын күзәтчелеге милке урнашкан җир кишәрлекләренә карата ирекле янгын күзәтчелеге иҗтимагый берләшмәләре;

13) янгыннарны профилактикалау һәм (яки) сүндерү һәм авария-коткару эшләрен башкару буенча эшчәнлек алып баручы ирекле янгын сүндерүчеләр;

5. Россия Федерациясе Салым кодексының 31 Бүлеге нигезендә салым түләүдән азат ителү хокукын раслаучы документлар җир кишәрлеге урнашкан урын буенча салым органнарына агымдагы елның 1 маена кадәр салым түләүләре буенча салым исәп-хисапларын һәм салым буенча салым декларациясен бирү өчен билгеләнгән срокларда физик затлар өчен тапшырыла.

6. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе советының «Җир салымы турында»гы 21.11.2014 елның 19 санлы карарын (Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советының 18.05.2015 №8, 19.10.2015 №19, 20.12.2017 №23, 29.10.2018, №29, 25.10.2019 № 16, 16.12.2019 № 22, 19.11.2020 № 12, 02.03.2021 №1, 18.07.2022 №9 карарлары редакциясендә) үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлегенең мәгълүмати

стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталы «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

8. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма халыкка игълан ителгән көннән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районының
шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе
Башлыгы А.Ә. Шәфигуллин